ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 26 от «27» 01 2020 г.

2020 елга халыкка торак-коммуналь
хезмәтләр күрсәтү тарифларын раслау турында

Россия Федерациясенең Торак Кодексы, 2003 нче елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә эшен оештыру принциплары турындагы» 131нче номерлы Федераль Закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1.Торак-коммуналь хезмәтләр өчен тарифларны түбәндәгечә расларга һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә:

- торак биналарны социаль биләү, муниципаль торак фонды биналарын биләү килешүләре нигезендә анда яшәүчеләр һәм күпфатирлы йортлар белән идарә итү алымын сайлау турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен тарифлар 1 кушымта нигезендә;

- торак урынын наемга алу өчен (социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарын найм шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен) 2 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны “Нократ” (“Вятка”) район газетасында һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының
2020 елның 27.01.2020 кабул ителгән
26 нче санлы
карарына 1 нче кушымта

## Торак биналарны социаль биләү, муниципаль торак фонды биналарын биләү килешүләре нигезендә анда яшәүчеләр һәм күпфатирлы йортлар белән идарә итү алымын сайлау турында карар кабул итмәгән торак милекчеләре өчен тарифлар

| Күрсәтелүче хезмәтнең исеме | Түләү алынучы үлчәү берәмлеге | Бер төр хезмәткә Алынучы түләү тарифы, сумнарда |
|---|---|---|
| Торак фонды белән идарә итү | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 2,42 |
| Йорт яны территориясен җыештыру | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 1,98 |
| Торак биналарны ремонтлау һәм йорт яны территориясен көндәлек төзекләндерү | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 2,09 |
| Техник хезмәт күрсәтү һәм йорт Эчендәге санитар-техник челтәрләрне ремонтлау | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 1,06 |
| Газ белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 0,22 |
| Электр энергиясе белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 0,91 |
| ГВС һәм җылылык энергиясен хисаплау җайланмаларына техник хезмәт күрсәтү | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 0.85 |
| гомуми файдалану урыннарын җыештыру | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м. | 2,69 |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль
районы Башкарма комитетының
2020 елның 27.01.2020 кабул ителгән
26 нче санлы
карарына 2 нче кушымта

Торак урынын наемга алу өчен
(социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарын найм шартнамәләре буенча торак урыннарын наемга алучылар өчен)
тарифлар

| Күрсәтелүче хезмәтнең исеме | Түләү алынучы үлчәү берәмлеге | Бер төр хезмәткә алынучы түләү тарифы, сумнарда |
|---|---|---|
| Тоак бинаны наймга алу | Гомуми яшәү мәйданының бер кв.м | 5,85 |